ТАТАРСТАН Республикасы
Аксубай
муниципальрайоны
муниципаль беремлеге
ИСКЕ ИЛДЕРЕК АВЫЛЫ

Республика ТАТАРСТАН
Аксубаевский
муниципальный район
муниципальное образование
село Старое Ильдеряково

**Исполнительный комитет Староильдеряковское сельское поселение**

**Сч. №40204810000000230012 к\сч.30101810000000000805 ИНН-1603004952 БИК 049205001 КПП-160301001 ОКПО- 94318576 ОАО «Ак Барс» Банк р.п.Аксубаево ЛБ 039140011 Ст Ил СП Тел.: 4-47-30**

# КАРАР

№3 2022 елның 31 гыйнвары

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында" Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 27.01.2002 ел, №57 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Ильдеряк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең 6964,68 (алты мең тугыз йөз алтмыш дүрт сум, 68 тиен), №1 кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, гарантияле исемлегенең чик күләмен билгеләү.
2. Үз көчен югалткан дип тану:
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 27 гыйнвары 2 номерлы карары.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Илтерәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе С.М. Маклаков

Иске Илтерәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
2022 елның 31 гыйнвары
3 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2022 елның 1 февраленнән.

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе<br>*( сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2764,68 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1000 |
| 4. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 3200 |
| Барлыгы | **6964,68** |

Иске Илтерәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
2022 елның 31 гыйнвары 3 номерлы
карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2022 елның 1 февраленнән

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе ( *сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2.Кәфенләү | 500 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2264,68 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1000 |
| 5. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 3200 |
| Барлыгы | **6964,68** |